## ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

№2 12 ноябрь 2020 ел

2021 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Мәлбагыш торак пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Мәлбагыш авыл җирлеге Мәлбагыш торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2021 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Түбән Якый авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрергә:

- Мәлбагыш торак пунктында Кооператив , Колхозчылар урамнары буенча җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту, юлларга вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Мәлбагыш авылында юлларны кардан чистарту(килешү буенча түләү);
- җәйге чорда Мәлбагыш авылында үлән чабу, территорияне җыештыру буенча хезмәтләр (килешү буенча эшләр өчен түләү, триммер өчен запас частьләр сатып алу, ягулык-майлау материаллары сатып алу);
- Мәлбагыш авылында «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне», «Халыкара инвалидлар көне», «Яңа ел», «Җиңү көне» бәйрәмнәрен оештыру һәм үткәрү (бүләк, сувенир продукция сатып алу);
- Мәлбагыш авылында торак пункт исеме белән стелла әзерләү һәм урнаштыру;
- Мәлбагыш авылында спорт чараларын оештыру һәм үткәрү (бүләк һәм сувенир продукция сатып алу);
- Мәлбагыш авыл җирлегендә урамнарны яктырту һәм урамнарны яктырту буенча хезмәт күрсәтү ( лампалар, яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җиһазлар сатып алу һәм алыштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Мәлбагыш авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми

сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Мәлбагыш авыл җирлеге башлыгы А.Й.Әхмәтшин